РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

17.09.2021

КАРАР

№ 1069-п

Социаль наем шартнамәләре буенча  яллаучылары яисә яллаучыларның гаилә әгъзалары яки милекчеләре булып ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, тәрбиягә алган гаиләләрдә опекада (попечительлектә) торучы   яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар һәм ятим балалар өчен оешмаларда торучы балалар һәм ятим балалар торган торак биналарның тиешле санитария һәм техник торышыннан файдалануны , торак биналар белән эш итүне тикшереп тору максатларында башкарыла торган тикшерүләр үткәрү буенча комиссия төзү турында

“Социаль наем шартнамәләре буенча  яллаучылары яисә яллаучыларның гаилә әгъзалары яки милекчеләре булып ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар торган торак биналардан файдалану һәм аларны саклауны,торак биналарның тиешле санитар һәм техник торышын тәэмин итүне, алар белән эш итүне тикшерүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында” 2019 елның 30 апрелендәге 374 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Социаль наем шартнамәләре буенча  яллаучылары яисә яллаучыларның гаилә әгъзалары яки милекчеләре булып ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, тәрбиягә алган гаиләләрдә опекада (попечительлектә) торучы   яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар һәм ятим балалар өчен оешмаларда торучы балалар һәм ятим балалар торган торак биналарның тиешле санитария һәм техник торышыннан файдалануны , торак биналар белән эш итүне тикшереп тору максатларында башкарыла торган тикшерүләр үткәрү буенча Комиссия төзергә.
2. Социаль наем шартнамәләре буенча  яллаучылары яисә яллаучыларның гаилә әгъзалары яки милекчеләре булып ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, тәрбиягә алган гаиләләрдә опекада (попечительлектә) торучы   яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар һәм ятим балалар өчен оешмаларда торучы балалар һәм ятим балалар торган торак биналарның тиешле санитария һәм техник торышыннан файдалануны , торак биналар белән эш итүне тикшереп тору максатларында башкарыла торган тикшерүләр үткәрү буенча Комиссия составын расларга (кушымта итеп бирелә).

3. Социаль наем шартнамәләре буенча яллаучылары яисә яллаучыларның гаилә әгъзалары яки милекчеләре булып ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, тәрбиягә алган гаиләләрдә опекада (попечительлектә) торучы яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар һәм ятим балалар өчен оешмаларда торучы балалар һәм ятим балалар торган торак биналарның тиешле санитария һәм техник торышыннан файдалануны , торак биналар белән эш итүне тикшереп тору максатларында башкарыла торган тикшерүләр үткәрү буенча Комиссия турында Нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары М.Р. Кәримовка йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 17 сентябрендәге 1069-п номерлы карары белән РАСЛАНГАН

**Социаль наем шартнамәләре буенча яллаучылары яисә яллаучыларның гаилә әгъзалары яки милекчеләре булып ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, тәрбиягә алган гаиләләрдә опекада (попечительлектә) торучы яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар һәм ятим балалар өчен оешмаларда торучы балалар һәм ятим балалар торган торак биналардан файдалану һәм аларны саклауны, торак биналарның тиешле санитар һәм техник торышын гамәлгә ашыруны, торак биналар белән эш итүне тикшереп тору максатларында башкарыла торган тикшерүләр үткәрү буенча**
**Комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Закирҗанов Расих Рәхимҗан улы | Саба муниципаль районы Башлыгы урынбасары, комиссия рәисе (килешү буенча) |
| Фазылова Резеда Рөстәм кызы | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге баш белгече, комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары | |
| Миникаев Альберт Илдар улы | Саба муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Рәхмәтуллин Вильнур Нәгыймулла улы | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече; |
| Вахитова Снежана Викторовна | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең баш белгече; |
| Территориясендә тикшерү үткәрелә торган торак бина урнашкан җирлек башлыгы (килешү буенча); | |
| Тикшерү үткәрелә торган торак урыны урнашкан күпфатирлы йорт белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма вәкиле (килешү буенча). | |

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2021 елның
17 сентябрендәге 1069-п
номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Социаль наем шартнамәләре буенча яллаучылары яисә яллаучыларның гаилә әгъзалары яки милекчеләре булып ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, тәрбиягә алган гаиләләрдә опекада (попечительлектә) торучы яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар һәм ятим балалар өчен оешмаларда торучы балалар һәм ятим балалар торган торак биналарның тиешле санитария һәм техник торышыннан файдалануны , торак биналар белән эш итүне тикшереп тору максатларында башкарыла торган тикшерүләр үткәрү буенча Комиссия турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

**1.1.** Социаль наем шартнамәләре буенча яллаучылары яисә яллаучыларның гаилә әгъзалары яки милекчеләре булып ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, тәрбиягә алган гаиләләрдә опекада (попечительлектә) торучы яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар һәм ятим балалар өчен оешмаларда торучы балалар һәм ятим балалар торган торак биналарның тиешле санитария һәм техник торышыннан файдалануны , торак биналар белән эш итүне тикшереп тору максатларында башкарыла торган тикшерүләр үткәрү буенча Комиссия Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан социаль наем шартнамәләре буенча яллаучылары яисә яллаучыларның гаилә әгъзалары яки милекчеләре булып ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, тәрбиягә алган гаиләләрдә опекада (попечительлектә) торучы яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар һәм ятим балалар өчен оешмаларда торучы балалар һәм ятим балалар торган торак биналарның тиешле санитария һәм техник торышыннан файдалануны , торак биналар белән эш итүне тикшереп тору максатларында башкарыла торган тикшерүләр үткәрү өчен булдырылган даими эшләүче коллегиаль орган булып тора.

**1.2.** Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары, әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

## 2. Комиссия вәкаләтләре

**2.1.** Комиссия вәкаләтләренә ,аларга карата Башкарма комитет (Башкарма комитетның структур бүлекчәсе) законнар нигезендә опека һәм попечительлек органының вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган ятим балаларның торак урыннарын файдалануны һәм саклауны, күрсәтелгән ятим балаларның торак урыннарының тиешле санитар һәм техник торышын гамәлгә ашыруга, күрсәтелгән ятим балаларның торак

урыннары белән идарә итүне  тикшереп тору максатларында планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрү керә(алга таба - тикшерү).

**2.2.** Тикшерүләрне уздыру тәртибе, нигезләре, ешлыгы һәм сроклары Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

**2.3.** Тикшерү барышында Комиссия Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган чараларны гамәлгә ашыра (гамәлгә ашыруны тәэмин итә).

**2.4.** Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча торак урынның сакланышын тикшерү акты (алга таба - тикшерү акты) төзелә, ул Комиссиянең тикшерү үткәрүдә катнашкан барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

**2.5.** Тикшерү актын рәсмиләштерүгә карата таләпләр Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

## 3. Комиссиянең эш тәртибе

**3.1.** Комиссия составына комиссия рәисе, секретаре һәм әгъзалары керә.

**3.2.** Комиссия утырышлары чираттагы елга раслана торган планлы тикшерүләрне үткәрү планын үтәү йөзеннән, шулай ук Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында,

Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында каралган планнар нигезендә планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигезләр булганда үткәрелә.

**3.3.** Комиссия рәисе, ә ул вакытлыча булмаган очракта  - Комиссия секретаре:

3.3.1. Комиссия утырышының көн тәртибен билгели;

3.3.2. Комиссия утырышларын үткәргәндә һәм тикшерүләр уздырганда җитәкчелек итә;

3.3.3. Тикшерү актын раслый.

**3.4.** Комиссия секретаре:

3.4.1. Комиссия әгъзаларына утырышлар һәм тикшерүләр уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында хәбәр итә;

3.4.2. Тикшерү үткәрү турында хокукый акт әзерләүне тәэмин итә. Күрсәтелгән актка таләпләр Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә;

3.4.3. Тикшерү үткәрү турында хәбәрнамә әзерләүне һәм әлеге хәбәрнамәне ятим балалар адресына җибәрүне тәэмин итә. Күрсәтелгән хәбәрнамәгә таләпләр Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә;

3.4.4. Тикшерү актын рәсмиләштерүне тәэмин итә.

**3.5.** Әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктындагы 3.4.1 пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә түбәндәге ысулларның берсе белән булса да башкарылырга тиеш:

- телефон аша хәбәр (шул исәптән мобиль телефонга);
- электрон почта адресына хәбәр;
- факсимиль элемтә ярдәмендә;
- мобиль телефон ярдәмендә кыска тест хәбәрләрен (СМС-хәбәрләрне) тапшыру;
- хәбәрләрне мессенджерлар ярдәмендә тапшыру;
- хәбәрнамәне теркәүне тәэмин итә торган башка чаралардан файдалану.

**3.6.** Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының билгеләнгән санының яртысыннан күбрәге катнашса, тулы хокуклы булып тора.

**3.7.** Комиссия әгъзасы тарафыннан үз тавышын кемгә дә булса тапшыру, шул исәптән Комиссиянең башка әгъзасына да, рөхсәт ителми.

**3.8.** Комиссия карарлары комиссия утырышында катнашучы комиссия әгъзалары санының гади күпчелек тавышларыннан ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булганда, хәлиткеч тавышка Комиссия рәисе (Комиссия рәисе булмаган очракта, Комиссия секретаре) ия.